**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ

# КАРАР

«31» октябрь, 2022 ел

№ 790

Бакча йортын торак йорты һәм торак йортны бакча йорты дип тану документациясен әзерләү һәм раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Закон 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. «Бакча йортын бакча йорты һәм торак йортны бакча йорты дип тану документациясен әзерләү һәм раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» әлеге карарга кушымтада бирелгән документларны расларга.

2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 29 октябренәге 725 номерлы «Бакча йортын бакча йорты һәм торак йортны бакча йорты дип тану документациясен әзерләү һәм раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында »гы карары үз көчен югалтуын танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән http://pestreci.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәйхетдиновка йөкләргә.

Муниципаль район
Башкарма комитеты җитәкчесе — А.В. Хәбибуллин